РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Кукеевского
сельского поселения
Рыбно Слободского
муниципального района

Новая ул., дом 5,
с.Кукеево, 422669

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Куки
авыл җирлеге
башкарма комитеты

Яна урамы, 5 нче йорт,
Куки авылы , 422669

Тел.: (84361) 30581 факс: (84361)30581, эл.адрес: Kuk.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2020 Күки авылы №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы "Җирле референдум турында" 23-ТРЗ номерлы Законы,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күки авылҗирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 30октябрендә узган гражданнар җыенында кабул ителгән 1, 2 номерлы карарын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торганТәртибен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы,Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры Мөхәмәтшина Рүзилә Габдулла кызына йөкләргә.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге
Башлыгы А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Күки авыл җирлегеБашкарма
комитетының 2020 елның
19мартындагыдагы
2 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**“Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә**
**гражданнарның үзара салым акчаларын җыю**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткәнгражданнар тарафыннан(белем алуның көндезге формасында укучы студентлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый) җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә
2020 елның 31 мартына кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәгеhttp://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итүһәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенчаТатарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
“____________ авыл (шәһәр) җирлеге”
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю Тәртибенә КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы“____________ авыл (шәһәр) җирлеге”
муниципаль берәмлегебюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №__________

Түләүченең Ф.И.А.и.
____________________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________
____________________________________________________нигезендә
Сезгә 2020 елның 31 мартына кадәр________________________________
_____________________чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган _________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: ______________________________________________
БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк
____________________________________________________________
Сч. №
Сч. № алучы
ИНН
КПП
КБК ____________________ ОКАТО ____________________
Түләүнең билгеләнеше
____________________________________________________________

Җитәкче
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

\- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ авыл (шәһәр) җирлеге”муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнелә торган ______________ сум күләмендәге түләүне түләү турындаХӘБӘРНАМӘ №__________
Түләүченең Ф.И.А.и. _________________________________________________
Адрес:_________________________________________________________
Алдым “____”_________________, 20 ел
________________________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм ________________җирлеге Башкарма комитетында кала.*